РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
АКСУНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКСУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

08 июль 2022 ел № 51-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Аксу авыл җирлегендә җирләрдән файдалану
һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында карар хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлеге советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге Советының 2013 елның 11 февралендәге 1-29 номерлы «Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» карары белән расланган Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» карары белән расланган Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә (2016 елның 28 июнендәге 14-2 номерлы, 2016 елның 21 сентябрендәге 18-1 номерлы, 2017 елның 23 сентябрендәге 36-1 номерлы, 2019 елның 11 февралендәге 65-1 номерлы, 2021 елның 23 июнендәге 24-1 номерлы, 2022 елның 01 мартындагы 41-2 номерлы, 2022 елның 04 маендагы 47-1 номерлы карарлары редакциясендә) (алга таба-Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1статья:

24 абзацны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясындагы 6 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексының 36 статьясындагы 1 өлешенең 1-3 пунктларында күрсәтелгән мөлкәтне үз эченә алган ике һәм аннан күбрәк фатирдан торган бина күпфатирлы йорт дип танылa. Күпфатирлы йорт шулай ук торак булмаган биналарның һәм (яки) машина-урыннарның аерым милекчеләренә караган, мондый күп фатирлы йортның аерылгысыз өлеше булып торган урыннарын үз эченә ала.».

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлеге Советының «Буа муниципаль районы Аксу авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында» 2013 елның 11 февралендәге 1-29 номерлы карары белән расланган (2016 елның 28 июнендәге 14-2 номерлы, 2016 елның 21 сентябрендәге 18-1 номерлы, 2017 елның 23 сентябрендәге 36-1 номерлы, 2019 елның 11 февралендәге 65-1 номерлы, 2021 елның 23 июнендәге 24-1 номерлы, 2022 елның 01 мартындагы 41-2 номерлы, 2022 елның 04 маендагы 47-1 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Аксу авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең яңа редакциясен хупларга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районы Аксу авыл
җирлеге башлыгы М.М. Хәйретдинов